**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# «Сабан туе» татар халык бәйрәмен уздыру турында

«Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә, җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып **карар бирәм:**

1. «Сабан туе» татар халык бәйрәмен түбәндәге көннәрдә уздырырга:

Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында, район үзәкләрендә (шул исәптән, республика әһәмиятендәге шәһәрләрдә) – 2025 елның 7-8 июнендә;

Чаллы шәһәрендә – 2025 елның 14 июнендә;

Татарстан Республикасы башкаласы Казан шәһәрендә – 2025 елның 21 июнендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җирле үзидарә органнары белән берлектә бәйрәм чараларын күрсәтелгән көннәрдә уздыруны оештыруны тәэмин итәргә.

3. Җирле үзидарә органнарына, җәмәгать берләшмәләренә, предприятиеләргә, оешмаларга «Сабан туе» татар халык бәйрәмен әлеге Указда билгеләнгән көннәрдә оештыруда һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 17 март
№ 204